**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.05.2017 Балык Бистәсе штп. № 106пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре исеменнән җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча вәкаләтләр бирү турында»2016 елның 2 июнендәге 82пи номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе район Советы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле вазыйфаи затлары турында һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлекләре урнаштыру схемаларын раслау буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә вәкаләтле органы турында» 2017 елның 29 маендагы XIX-Зномерлы карарын кабул итү сәбәпле һәм муниципаль хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре исеменнән җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча вәкаләтләр бирү турында» үз көчен югалткан дип санау хакында " 2016 елның 2 июнендә кабул ителгән 82пи номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы ,Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин